РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 сентябрь 2018 ел Буа шәһәре № 260/ИК-п

Опека һәм попечительлек өлкәсендә
дәүләт хезмәтләрен күрсәтү административ
регламентны раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 28 августындагы 1316 номерлы боерыгы, Татарстан Республиакасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 18 июнендәге 3680/12 номерлы, 3681/12 номерлы, 3683/12 номерлы, 2012 елның 21 июнендәге 3790/12 номерлы, 2012 елның 22 июнендәге 3873/12 номерлы, 3844/12 номерлы, 3845/12 номерлы, 2012 елның 27 июнендәге 3938/12 номерлы, 3939/12 номерлы, 3940/12 номерлы боерыклары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

1.1. Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү буенча дәүләт хезмәтләрен күрсәтү административ регламентны (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга һәм http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча ТР Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керүен билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче М.М. Юнысовага йөкләргә.

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Кәмәртдинов

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 7 сентябрендәге
260/ИК-п номерлы
карарына кушымта

**Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү буенча дәүләт хезмәтләрен күрсәтү административ регламентны**

1.1. Әлеге Регламент опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү буенча дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең стандартлары һәм тәртипләрен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гариза бирүченең яки опекага алынучының яшәү урыны буенча күрсәтелә (Башкарма комитет тарафыннан).

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге (алга таба – бүлек).

1.3.1. Башкарма комитет урнашкан урын: 422430, ТР, Буа шәһәре, Жорес ур., 110А.

Опека һәм попечительлек бүлегенең кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен.

Дүшәмбе – җомга 8-00 дән 17-00 кадәр, төшке аш 12-00 дән 13-00 кадәр.

Керү шәхесне раслаучы документ буенча башкарыла.

1.3.2. Бүлек телефоны: 8 (84374) 3 40 34.

1.3.3. Башкарма комитетның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә рәсми сайты адресы: http://buinsk.tatarstan.ru (алга таба – «Интернет» челтәре).

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет биналарында урнаштырылган, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, дәүләт хезмәтләре турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Башкарма комитетның рәсми сайтында (http:// buinsk.tatarstan.ru)

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) опека һәм попечительлек органына телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефон аша);

4) опека һәм попечительлек органына язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать итеп.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә хәл ителә:

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ ГК) («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 05.12.1994, №32 3301 б., «Российская газета», 238-239, 08.12.1994);

1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гаилә кодексы (алга таба – РФ ГК) («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 01.01.1996, №1 16 б., «Российская газета», №17, 27.01.1996);

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 28.04.2008, №17 1755 б., «Российская газета», 30.04.2008 №94, «Парламентская газета», 07.05.2008, №31-32);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 02.08.2010, №31 4179 б., «Российская газета», №168, 30.07.2010);

РФ Хөкүмәтенең «Балигъ булмаган гражданнарга мөнәсәбәтле опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары (алга таба 423 нче карар) («Россия Федерациясе законнар җыентыгы», 25.05. 2009, №21 2572 б., 2012 ел, №19 2416 б., №21 2644 б., №37 5002 б., «Российская газета», 27.05.2009, №94);

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба – ТР ГК) («Республика Татарстан», 16.01.2009, №8, «Ватаным Татарстан» 17.01.2009, №8, «Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы», №1, гыйнвар, 2009 ел);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) («Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы», №2, февраль 2004 ел, «Ватаным Татарстан», 2.03.2004, №43-44, «ТР Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары җыентыгы», 26.05.2004, №21);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек өлкәсендә муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы («Ватаным Татарстан», 22.03.2008, №54, «Республика Татарстан», 25.03.2008, №60-61, «Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы», №3, март 2008 ел);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү тәртибе һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга, попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү тәртибен раслау турында» 2011 елның 2 мартындагы 593/11 нче номерлы боерыгы (ТР МһФМ 593/11 нче номерлы карары) («Республика Татарстан», 19.04.2011, №78, «Ватаным Татарстан», 12.07.2011, №127, «ТР Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика

башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары җыентыгы», 14.02.2012, №12);

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2013 елның 20 декабрендәге 4-37 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы (2015 елның 28 маендагы 1-49 номерлы, 2016 елның 15 июлендәге 9-1 номерлы, 2017 елның 15 сентябрендәге 6-24 номерлы Буа муниципаль районы Советы карарлары редакциясендә);

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2015 елның 17 апрелендәге 3-47 номерлы карары белән расланган, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә;

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2016 елның 24 февралендәге 10-5 номерлы карары белән расланган, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы опека һәм попечительлек буенча бүлек турында Нигезләмә;

2015 елның 7 апрелендәге 81-р номерлы карар белән расланган, Буа муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаган гражданнарга мөнәсәбәтле опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруны оештыру һәм башкару буенча баш белгечнең вазифа инструкциясе.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләпләренең исеме | Стандарт таләпләренең эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәтнең исеме | Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү. | 48-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы;<br>ТР ГК 137, 141(1) һәм 146 статьялары |
| 2.2. Хезмәт күрсәтү органының атамасы | Башкарма комитет.<br>Дәүләт хезмәтен үтәүче – Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек буенча бүлек. | |
| 2.3 Хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе | Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат. | ТР ГК 137, 141(1) һәм 146 статьялары;<br>ТР МһФМ 593/11 номерлы боерыгы 8 пункты |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү срогы | Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен, үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга акча чаралары билгеләү, гариза бөтен кирәкле документлар белән кабул ителгән (теркәлгән) көннән 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла. | ТР ГК 138 статьясы |
| 2.5. Законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәк һәм | 1) Акча чараларын билгеләү турында (бүләкләүләр турында) гариза;<br>2) баланың туу турындагы таныклыгы (паспорты) | ТР ГК 138 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| мәҗбүри булган хезмәтләр өчен кирәкле, гариза бирүче тәкъдим итәргә тиешле документларның тулы исемлеге | күчермәсе;<br>3) баланы бердәнбер яки ике ата-анасы да тәрбияләмәве фактын дәлилләүче документларның күчермәсе (ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында суд карары, үлем турындагы таныклык һ.б.);<br>4) баланың опекун яки попечитель, тәрбиягә алган ата-ана белән бергә яшәве турында яшәү урыныннан белешмә;<br>5) 16 яшьтән олырак баланың белем бирү оешмасында укуы турында белешмә;<br>6) балага опека һәм попечительлек билгеләү турында опека һәм попечительлек органы карарыннан өземтә;<br>7) халыкны социаль яклау территориаль органыннан түләүләр туктатылуы турында белешмә. | |
| 2.6. норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган, гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы документларның тулы исемлеге | Ведомствоара бәйләнеш кысаларында алына:<br>- баланың опекун (попечитель), тәрбиягә алган ата-ана белән бергә яшәве турында яшәү урыныннан белешмә (баланың яшәү урыны буенча йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә;<br>- халыкны социаль яклау территориаль органының бала өчен ай саен пособие түләүләре туктатылуы турында белешмәсе. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, дәүләт хезмәтен тәкъдим итүче башкарма хакимият органы тарафыннан раслауны таләп иткән, дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен | 1. Тәкъдим ителгән документларның 2.5 пунктта | |

| | | |
|---|---|---|
| кирәкле булган документларны кире кагу өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>2. Бирелгән документларда алдан килешенгән төзәтмәләр.<br>3. Фактик яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәү. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки кире кагу өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары түләү шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга түләүләр түбәндәге очракларда билгеләнә алмый:<br>а) баланың балигълык яшенә җитүе;<br>б) баланы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларга тулысынча дәүләт тарафыннан тәэмин ителүгә урнаштыру;<br>в) баланы уллыкка алу;<br>г) балигъ булмаган опекага алынучыны эшкә урнаштыру;<br>д) опекага алынучының рәсми өйләнүе (кияүгә чыгуы);<br>е) балигъ булмаган опека алынучының тулысынча хокукка сәләтле булуын белдерү (эмансипация);<br>ж) опекун яки попечительне үз вазифаларын башкарудан азат итү, читләштерү;<br>з) баланы әти-әнисенә (икесенең берсенә) кайтару;<br>и) опекун яки попечительнең, опекага алынучының үлеме;<br>к) әти-әнисе аларны тәрбияләп һәм карап тотуны шәхсән башкара алган (озак вакытлы эш командировкаларында булган, балалардан аерым яшәгән, әмма аларны карарга һәм тәрбияләргә һ.б. бөтен шартлары булган), ләкин үз ирекләре белән, шул исәптән «Опека һәм | ТР ГК 139 һәм 141 статьялары<br>ТР МҺФМ 593/11 номерлы боерыгы 12 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | попечительлек турында»гы Федераль законның 13 статьясы 1 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, аларны башка затларга опекага яки попечительлеккә биргән балаларга акчалата чаралар билгеләнми;<br>л) ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тулысынча дәүләт тарафыннан тәэмин ителүдә булган балаларга акчалата түләүләр билгеләнми.<br>Үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга ай саен акчалата бүләкләнүләрне түләү, балигъ булмаган балага карата түләүле шартларда опека һәм попечительлек күрсәтү турындагы килешүнең, шул исәптән тәрбиягә алган гаилә турындагы килешүнең шартларын тиешле итеп үтәмәгән очракта туктатыла. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә тәкъдим ителә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган, хезмәт күрсәткәнгә түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүмат | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта максималь көтү срогы | Мөрәҗәгать итүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтү) максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт | Гариза кабул ителгән көндә. | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтү турында соравын теркәү срогы | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелүче биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән күрсәтелгән объектларның, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә, инвалидлар өчен үтемлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиале мәгълүматны урнаштыру һәм оформить итүгә таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы, документларны оформить итү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына инвалидларның киртәсез үтеп керүе тәэмин ителә (бүлмәгә керү-чыгу юлында һәм аның чигендә йөргәндә уңайлыклар).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиале мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләргә уңайлы, шул исәптән инвалидларның чикле мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтенең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре булып тора:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>3) мөрәҗәгать итүче яшәгән районда опека һәм попечительлек органының булуы. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация Интернет-кабул итү бүлмәсе аша башкарыла.<br>Гаризалар һәм документлар электрон формада Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (адрес: http://uslugi.tatar.ru/) аша юллана, документларның оригиналларын алга таба рөхсәт алганда тәкъдим итәргә кирәк. | |

### 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкарылу сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкаруның үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү:

1) гариза бирүчегә консультация ясау;

2) гариза бирүчене кабул итү, документлар кабул итү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара сорауларны формалаштыру һәм җибәрү;

4) опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү билгеләү турында карарны әзерләү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру;

6) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу сәбәпләре булган очракта, аңлатма хаты җибәрү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча эзлекле гамәлләрнең блок-схемасы 3 нче кушымтада тәкъдим ителә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация ясау.

Гариза бирүче үзе шәхсән телефон, электрон почта аша (адрес: bua@tatar.ru) һәм (яки) хат белән опека һәм попечительлек органына дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итә.

Опека һәм попечительлек органы хезмәткәре, мөрҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте алу өчен документларның исемлеге, шул исәптән составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирә.

Әлеге пункт буенча билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: консультация бирү, дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы, эчтәлеге буенча искәрмәләрне җиткерү.

3.3.Гариза бирүчене кабул итү, документлар кабул итү.

3.3.1. Гариза бирүчедән  шәхсән, әлеге Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документлар опека һәм попечительлек органына тапшырыла.

3.3.2. Опека һәм попечительлек органының кабул итүче белгече башкара:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

документларның барлыгын тикшерә;

тәкъдим ителгән документларның тиешле таләпләргә туры килүен (документ күчерелмәләрен кирәкле формада үтәлеше, бозып төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килештерелмгән төзәтүләр юклыгын) тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән, кире кагу өчен нигез булып торган сәбәпләр булмаган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә гариза кабул итү датасын һәм тиешле документлар исемлеген хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.3. подпунктында каралган процедуралар башкарыла.

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән, кире кагу өчен нигезләр булган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече, мөрәҗәгать итүче гариза биргәндә шәхсән үзе гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуын хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрнең эчтәлеген язмача аңлатма белән документларны аңа кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризалар теркәү журналында теркәү язмасы, расписка яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Опека һәм попечительлек органы белгече әлеге Регламентның 2.9. пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә кире кагу өчен нигез булырлык очракларны тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече кире кагу турында хат әзерли һәм аны имзалану көненнән 2 көнлек срок эчендә мөрәҗәгать итүчегә җиткерә. Бер үк вакытта гариза бирүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карарга шикаять белдерү тәртибе аңлатыла һәм әлеге Регламентның 3.7. пунктында күрсәтелгән поцедуралар башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, мөрәҗәгать итүче китергән документлардагы мәгълүматларны тикшерү эше оештырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар, гариза кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирүне әзерләү яки кире кагу турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара сорауларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Опека һәм попечительлек органы белгече ведомствоара электрон бәйләнешләр системасы чаралары аша электрон формада сораулар юллый:

- баланың яшәү урыны буенча йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә тәкъдим итү турында;

- халыкны социаль яклау территориаль органының балага айлык пособиеләр түләнүе туктатылу турында белешмә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар, моннан алдагы процедура төгәлләнгән көннән алып бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында сораулар җибәрү.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан, опека һәм попечительлек органы сораулары буенча, автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- сорауны эшкәртү һәм соралган мәгълүматларны эзләү;

- ведомствоара электрон бәйләнешләр системасы чаралары аша соралган мәгълүматларны формалаштыру, яисә, соралган мәгълүматлар булмаган очракта, соралган мәгълүматларны тәкъдим итә алмауның сәбәпләрен күрсәтеп хәбәр җибәрү.

Әлеге пунктта каралган процедуралар, опека һәм попечительлек органыннан сорау килгән көннән алып, 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: сорауга җавап яки әлеге Регламентның 3.4. пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны бирүне кире кагу турында хәбәр җибәрелә.

3.5. Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү турында карар әзерләү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек органы белгече тәкъдим ителгән документлар нигезендә опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны)

карап тору өчен акча чаралары билгеләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү турында карар проектын яки опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү турында карарны кире кагу турында хат әзерли һәм рөхсәт итү турындагы хатның проектын яки кире кагу турындагы хатны алга таба раслату өчен Башкарма комитет җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәгәлләнгән көннән алып ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләүне билгеләү турында карар чыгару яки 3.7. пункт нигезендә әзерләнгән кире кагу турында язмача карар бирү.

3.5.2. Опека һәм попечительлек органы белгече, рөхсәт турында имзаланган хатны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүчегә тапшыра (җибәрә). Тискәре нәтиҗә очрагында, кире кагу турындагы хатны үзе шәхсән кулларга тапшыра яки 3.7. пункт нигезендә заказлы хат итеп, почта аша белдерү кәгазе белән җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпунктында каралган процедуралар тәгәлләнгән көннән алып бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында хәбәр итү.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт нәтиҗәсен тапшыру.

3.6.1. Опекунга яки попечительгә баланы (балаларны) карап тору өчен билгеләнгән акча чараларын опекунга яки попечительгә түләү, аларны алуга сәбәпләр барлыкка килгәннән башлап чор өчен опекунның яки попечительнең опекага алынучыны карап тотуга чыгымнарын кайтару белән, опека һәм попечительлек органы баланы (балаларны) карап торуга акчалата чаралар билгеләү турында карар чыгарган көннән башкарыла.

Үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекунга, попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага бүләкләүләр түләүле шартларда опека һәм попечительлекне башкару турында боерык бирүче акт (карар) һәм баланы (балаларны) тәрбиягә алучы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турындагы килешү кабул ителгән көннән билгеләнә.

Әлеге пунктта каралган процедуралар опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага ай саен тулы күләмдә агымдагы айның 20 числосыннан да соңармыйча башкарыла яки опекун яки попечитель, тәрбиягә алган ата-ана рөхсәте белән шул ук срокта банкта ачылган шәхси счетка яисә почта элемтәсе бүлеге аша җибәрелә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат юллау.

3.7.1. Рөхсәт бирүне кире кагу турында карар кабул ителгән очракта опека һәм попечительлек органы белгече хезмәт күрсәтүне кире кагу турындагы хат проектын әзерли.

Әзерләнгән хат проектын имзалау өчен Башкарма комитет җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта каралган процедуралар кире кагу өчен сәбәпләр ачыкланган вакыттан ике эш көне дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзалауга җибәрелгән кире кагу турындагы хат проекты.

3.7.2. Башкарма комитет җитәкчесе кире кагу хаты проектын имзалый һәм опека һәм попечительлек органы белгеченә кайтара.

Әлеге пунктта каралган процедуралар 3.7.1. подпунктында каралган процедуралар төгәлләнгән вакыттан алып бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: кире кагу турындагы имзаланган хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек органы белгече кире кагу турындагы хатны гариза язучыга җиткерә. Бер үк вакытта гариза бирүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карарга шикаять язу тәртибе аңлатыла.

Әлеге пунктта каралган процедуралар 3.7.2. подпунктында каралган процедуралар төгәлләнгән вакыттан алып бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.8. Дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүче күпфункцияле үзәкләр аша күрсәтү.

3.8.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.8.2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүче күпфункцияле үзәк аша дәүләт хезмәте билгеләнгән тәртиптә расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүче күпфункцияле үзәк эше регламенты нигезендә күрсәтелә.

3.8.3. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүче күпфункцияле үзәктән дәүләт хезмәтен алуга документлар керсә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3-3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүче күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм юк итү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешен тикшерү, опека һәм попечительлек органы вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәлләр кылмауга) һәм карарларына карата шикаятьләр белдергән мөрәҗәгатьләргә карата җаваплар әзерләү һәм карарлар кабул итүне үз эченә ала.

Административ процедураларны башкару үтәлешен контрольдә тоту формалары:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларына хокукый экспертиза үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалаштыру тора;
- эш башкаруны алып баруга билгеләнгән тәртиптә тикшерү үткәрү;
- дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлаштырылган һәм планнан тыш була ала. Тикшерүләр үткәргәндә дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле (комплекслы тикшерүләр), яки гариза язучының конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндәге гамәлләр башкарылуын контрольдә тоту һәм карарлар кабул итү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр Башкарма комитет җитәкчесенә тапшырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклеге сакланышы артыннан агымдагы контроль дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затларның исемлеге опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр белән һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очрагы ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында тикшерелмәве өчен җавап бирә.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 нче бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне үз вакытында һәм (яки) тиешле итеп башкармаган өчен җавап бирә.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителгән карарлар һәм гамәлләр (гамәлләр кылмау) өчен Законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тота.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүгә контроль опека һәм попечительлек органының дәүләт хезмәте күрсәткәндәге эшчәнлеге ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртипләре турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судкача карау мөмкинлеге аркылы башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук вазыйфаи затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәлләр кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек органы белгечләре гамәлләренә (гамәлләр кылмауларына) судка кадәрге тәртиптә, Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитетына шикаять белдерергә хокуклы.

Гариза бирүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында соравын теркәү срогы бозылу;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдә баш тарту;

кире кагу өчен сәбәпләр федераль законнарда һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы хокукый норматив актларында каралмаган килеш тә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

дәүләт хезмәте күрсәтү органының, дәүләт хезмәте күрсәтү органының вазыйфаи затының җибәрелгән хаталарны төзәтүдән һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә документларда киткән яки ул хаталарны төзәтү өчен куелган сроклар бозылган очракта хаталарны төзәтүдән баш тартуы.

дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басмадагы хата һәм ялгышлыкларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләр өчен билгеләнгән срокларның бозылуы.

5.2. Шикаять кәгазьдә язма формада яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүче күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен, Татарстан Республикасы муниципаль районы рәсми сайтын (http://www.buinsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре (функцияләре) бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре (функцияләре) бердәм порталын (http://gosuslugi.ru) файдаланып, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы – аны теркәү көненнән алып 15 эш көне дәвамында. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән басмадагы хата һәм ялгышлыкларны төзәтүдән баш тартуына яисә мондый төзәтүләр өчен билгеләнгән срокларның бозылуына шикаять белдергән очракта – аны теркәү көненнән алып 5 эш көне дәвамында.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлары яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүматлары, шулай ук гариза бирүчегә җавап юллар өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслар) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органны тәкъдим итүче вазыйфаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органны тәкъдим итүче вазыйфаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмавын нигезләгән дәлилләр;

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны бирүче дәүләт хезмәте алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе шикаятьне тикшерү нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте тәкъдим итүче орган тарафыннан җибәрелгән басмадагы хата һәм ялгышлыкларны төзәтүдә кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында түләтү каралмаган акча чараларын гариза бирүчегә кайтару, шулай ук башка формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге Регламентның 5.1.7. подпунктында күрсәтелгән карарны кабул итүдән соң киләсе көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне тикшерү барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять очрагы ачыкланса шикаятьләрне тикшерү буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат кичектермәстән булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

ТР Премьер-министры урынбасары –
ТР мәгариф һәм фән министры
Р.Т. Борһановка

опекуннан (тәрбиягә алган ата-анадан һ.б.ш.)

__________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
__________________________________________

түбәндәге адрес буенча яшәүче:
__________________________________________
(тулы адрес)
__________________________________________

паспорт:____________________________________
(серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
__________________________________________
__________________________________________

## ГАРИЗА
гражданинның баланы (балаларны) карап тотуга
акча чараларын билгеләү һәм түләү турында

Сезне балигъ булмаган опекага алынучыга(-ларга)
________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган датасы)
________________________________________________________________

ай саен, (бер тапкыр бирелә торган) пособие билгеләүне сорыйм.

Дата Имза

Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аның күрсәтелүенә агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының Опека һәм попечительлек бүлеге**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Опека һәм попечительлек бүлегенең баш белгече | (84374) 3 40 34 | Gulnaz.Halitova@tatar.ru |
| Опека һәм попечительлек бүлегенең баш белгече | (84374) 3 40 34 | Aygul.Fashutdinova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (84374) 3 10 93 | bua@tatar.ru |
| Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче | (84374) 3 12 02 | Milyausha.Yunusova@tatar.ru |

Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә алган ата-анага баланы (балаларны) карап тору өчен акча чаралары билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә алган ата-аналарга тиеш булган бүләкләүләрне түләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча эзлекле гамәлләрнең блок-схемасы**

